**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Советская, д.22,

с. Азеево,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 22,

Акъяр авылы,423190

тел.: (8- 84348) 3-71-31, факс: (8-84348) 3-71-61 Azeev.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2023 нче елның 14 ноябре | № 20

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия турында

РФ Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32, 33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 4 өлешенә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге территориясен тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы территориясен планлаштыру, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклау, физик һәм юридик затларның, шул исәптән җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү өчен, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия составын расларга (2 нче кушымта).
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының рәсми сайтында "бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, «Интернет" мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге башлыгы                                                  Д.С.Гайнуллин